КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 29 май г.Казань № 389

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар ризыгын җитештерү өчен сөт китерүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә алынмый калган керемнәрен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 30 ноябрь, 929 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар ризыгын җитештерү өчен сөт китерүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә алынмый калган керемнәрен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 30 ноябрь, 929 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 25 август, 740 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «субсидияләр» сүзен «субсидия» сүзенә алмаштырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән Балалар ризыгын җитештерү өчен сөт китерүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә алынмый калган керемнәрен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен расларга.»;

әлеге карар белән расланган Балалар ризыгын җитештерү өчен сөт китерүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә алынмый калган керемнәрен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин